| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПАС МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БОЛГАР ШӘҺӘРЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | **БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ 24 «08» 07 2024 ел

«Күпфатирлы йортта бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 15 ноябрендәге 83 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 декабрендәге 608-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Күпфатирлы йортта бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 15 ноябрендәге 83 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Күпфатирлы йортта бинаны яңадан урнаштыруны һәм (яисә) яңадан планлаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» кушымтасының 1.5 пунктындагы 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Күпфатирлы йорттагы бинаны яңадан планлаштыру мондый бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән гыйбарәт, һәм (яисә) яңа биналар барлыкка килүдән, шул исәптән РФ ТКсының 40 статьясында каралган очракларда, һәм (яисә) аның эчке планлаштырылуын үзгәртүдән (шул исәптән бинаның чикләрен һәм (яисә) мәйданын үзгәртүдән тыш). Яңадан планлаштыру нәтиҗәсендә шулай ук чиктәш биналарның чикләре һәм (яисә) мәйданы да үзгәрергә мөмкин. Планлаштыруны яңадан төзү биналарның чикләре һәм (яисә)

мәйданы (биналары) турында яисә төзелгән биналарның дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру һәм төзелгән биналарга хокукны дәүләт теркәвенә алу турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү зарурлыгына китерә.»

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://spasskiy.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Болгар шәһәр Башкарма комитеты житәкчесе А.В.Костина

БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ